## Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге составына керүче Алексеевка авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

## КАРАР

**2020 елның 12 ноябре** **№3**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының «Беловка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлеге Советының составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» карары нигезендә, 2019 елның 05 ноябрендәге 102 номерлы Татарстан Республикасы Аксубай авыл җирлеге Советы карары белән, Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлегенең Алексеевка авылында 2020 елның 12 ноябрендә узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш,һәр балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?"

**1. Беловка авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**
- Алексеевка торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: (грунт күтәрү, грейдерлау, вак таш салу, тигезләү ,килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- авыл юлларына вак таш җәю өчен вак таш сатып алу
- Алексеевка авыл җирлегенең Беловка торак пункты чикләрендә юлларны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу).

« РИЗА»   « КАРШЫ»   “ТЫЕЛЫП КАЛДЫ”

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә. Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 99 граждан кертелгән, җыенда катнашкан гражданнар саны 57 граждан.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
" РИЗА " позициясе өчен халык җыенында катнашучы 57 кеше тавыш бирде;
"Каршы" позициясе өчен 0 кеше тавыш бирде.

"тыелып калды" позициясе өчен 0 кеше  табыш бирде.
Бәян ителгәннәрдән чыгып,халык җыены  карар итте:

1.Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының Беловка авыл җирлеге составына керуче Алексеевка авылында гражданнар җыенын узган дип танырга, гражданнар җыенының нәтиҗәләре - дөрес.

2. Сорау буенча карарны танырга: "Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Беловка авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм көндезге формада белем алучы студентлардан тыш,һәр балигъ булган һәр кешедән, 2021 елда 500 сум күләмендә үзара салым акчасы кертергә һәм алынган акчаны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә ризамы?

**Беловка авыл җирлеге чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге**

- Алексеевка торак пункты чикләрендә юл полотносы урнаштыру, шул исәптән: (грунт күтәрү, грейдерлау, вак таш салу, тигезләү ,килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- авыл юлларына вак таш җәю өчен вак таш сатып алу
- Беловка авыл җирлегенең Алексеевка торак пункты чикләрендә юлларны кышкы карап тоту (юлларны кардан чистарту,запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү, ягулык-майлау материаллары сатып алу) кабул ителгәнгә.

3.Әлеге карарны Беловка авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә, Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга, http://aksubaevo.tatar.ru һәм Татарстан Республикасы мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/

4. Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен әлеге карарны җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче
Татарстан Республикасы Аксубай
муниципаль районының Беловка
авыл җирлеге башлыгы  И. Р. Мәхмүтов